Проект

**Төп гомуми белем бирү программалары буенча
төп дәүләт имтиханы (ТДИ) рәвешендә
дәүләт йомгаклау аттестациясе**

ТАРИХ буенча 2016 елда төп дәүләт имтиханы үткәрү
өчен контроль үлчәү материаллары (КҮМ)
**үзенчәлекләре (спецификация)**

«ПЕДАГОГИК ҮЛЧӘНЕШЛӘР ФЕДЕРАЛЬ
ИНСТИТУТЫ»
Федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесе
тарафыннан әзерләнде



**ТАРИХ буенча
2016 елда төп дәүләт имтиханы үткәрү өчен контроль
үлчәү материаллары (КҮМ)
үзенчәлекләре**

**1. ТДИ өчен КҮМнең билгеләнеше** – чыгарылыш укучыларын дәүләт йомгаклау аттестацияләве максатларында гомуми белем бирү оешмаларының IX сыйныф чыгарылыш укучыларын тарих буенча гомуми белем әзерлеге дәрәҗәсен бәяләү. Имтихан нәтиҗәләре укучыларны урта мәктәпнең профильле сыйныфларына кабул иткәндә кулланыла ала.

ТДИ «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы нигезендә үткәрелә.

**2. КҮМнең эчтәлеген билгеләүче документлар**

Имтихан эшенең эчтәлеге Төп гомуми белем бирү дәүләт стандарты федераль компоненты базасында (Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2004 елның 5 мартындагы «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта (тулы) гомуми мәгариф дәүләт стандартлары федераль компонентын раслау турында» 1089 номерлы боерыгы) һәм Ватаныбыз тарихы буенча яңа укыту-методик комплексы концепциясенең бер өлеше булып торган Тарихи-мәдәни стандарт нигезендә билгеләнә.

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә
күзәтчелек буенча федераль хезмәте

### 3. КҮМ эчтәлеген сайлап алуга, структурасын эшләүгә якын килү

Тикшерелүче эчтәлек элементларын сайлап алуга һәм биремнәрне конструкцияләүгә якын килү Тарих буенча төп гомуми белем бирү үрнәк программасында конкретлаштырылган югарыда күрсәтелгән таләпләрне исәпкә алып билгеләнде һәм тарихи белемнәр составына да, укучылар үзләштерергә тиешле осталыкка да таләпләрне эченә ала. Түбәндәгеләрне исәпкә алу принципиаль дәрәҗәдә мөһим иде:

– төп мәктәптә тарихи белем бирү максатларын;
– төп мәктәпнең тарих курсы спецификасын;
– тарихи мәгарифнең белемнәргә генә түгел, беренче чиратта эшлеклелек компонентына йөз тоту.

Төп мәктәптә «Тарих» фәненең эчтәлеге үз эченә ике курсны ала: уку-укыту процессында өстенлекле урынны алып торучы Россия тарихын һәм гомуми тарихны. Имтихан эшендә гомуми тарих элементлары кертелгән Россия тарихы буенча белемнәрне тикшерүгә юнәлтелгән биремнәр (Россиянең халыкара мөнәсәбәтләре һәм тышкы сәясәте тарихы буенча, сугышлар тарихы буенча темалар; икътисад һәм мәдәният тарихының аерым мәсьәләләре h.б.) китерелгән.

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте



### 4. ТДИ имтихан моделенең БДИ КҮМ белән элемтәсе

Төп гомуми белем бирү дәүләт стандарты федераль компоненты төп һәм өлкән мәктәп курсы өчен дәүләт йомгаклау аттестациялəвендә дəвамлылыкны тәэмин итәргә мөмкинлек бирә. ТДИның тарих буенча БДИ белән дәвамлылыгы тикшерелүче эчтәлек элементларын һәм танып-белү эшчәнлеге төрләрен сайлап алуга якын килүдә дә, тулаем имтихан эше структурасында һәм аерым биремнәр рәвешләрендә дә күренә.

Шул ук вакытта укучыларның танып-белү яшь мөмкинлекләре һәм төп мәктәпнең эчтәлек киңлекләрен һәм белемнәргә, осталыкка таләпләр дәрәҗәсен чикләүче тарих курсы спецификасы исәпкә алына.

### 5. КҮМ структурасы һәм эчтәлеге характеристикасы

Эш борынгыдан алып, хәзерге вакыткача тарих курсы эчтәлеген үз эченә ала.

Биремнәрнең гомуми саны – 35.

Эш ике өлештән тора.

1 өлештә дөрес җавап номерына, саннар эзлеклелегенә яисә сүзгә (сүзтезмәгә) туры килгән бер сан рәвешендәге кыска җавап белән 30 бирем бар.

2 өлештә киң җавап белән 5 бирем бар. Бу өлеш биремнәрен үтәүне тикшерү махсус эшләнгән

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

критерийлар нигезендә экспертлар тарафыннан уздырыла.

*1 нче таблица. Биремнәрне имтихан эше өлешләре буенча бүлү*

| Эш өлеш-ләре | Бирем-нәр саны | Максималь башлангыч балл | 44 кә тигез максималь башлангыч баллдан процент | Биремнәр төре |
|---|---|---|---|---|
| 1 өлеш | 30 | 32 | 72,7 | Кыска җавап белән |
| 2 өлеш | 5 | 12 | 27,3 | Киң җавап белән |
| Бар-лыгы | 35 | 44 | 100 | |

**6. КҮМ биремнәрен эчтәлек, тикшерелүче осталык һәм эшчәнлек ысуллары буенча бүлү**

Эшнең 1 өлешендә биремнәр шартлы рәвештә гомуми чорларны исәпкә алып аерып күрсәтелгән тарихи дүрт чорның берсенә караган тематик блокларга бүленгән: 1) VIII–XVII гасырлар; 2) XVIII–XX гасыр башы; 3) 1914–1945 еллар; 4) 1945-2012 еллар. КҮМнең һәр вариантына Бөек Ватан сугышы тарихы буенча ике бирем (14, 15) кертелгән. КҮМнең һәр варианты аерым

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте



позицияләрендә Ватаныбыз тарихының иң күренекле эшлеклеләре (9, 19) мәдәният тарихының төп фактлары (10, 20) турында белемнәрне; тарихи карта, схема (21), иллюстратив материал (22) белән эшләү осталыгын тикшерүгә юнәлтелгән биремнәр күрсәтелә.

Эшнең башлыча тарихи белем бирү барышында формалашкан белемнәрне тикшерүгә юнәлтелгән 23-35 биремнәр тарихның VIII гасырдан алып 2012 елгача теләсә кайсы чорына карарга мөмкин. Шул ук вакытта 23-35 биремнәрнең һәркайсында тарихның төрле аспектлары: икътисад һәм социаль мөнәсәбәтләр, дәүләтнең эчке һәм тышкы сәясәте, матди һәм рухи мәдәният тарихы, аерым тарихи шәхесләр тормышы һәм эшчәнлегә каралырга мөмкин.

Эштә түбәндәге белемнәр тикшерелә.

*2 нче таблица. Биремнәрнең тикшерелүче белемнәр һәм эшчәнлек ысуллары буенча бүленеше*

| № | Тикшерелүче әзерлек дәрәҗәсе элементлары | Код[1] | Биремнәр саны | Максималь башлангыч балл | Тулысынча эш өчен 44 кә тигез максималь башлангыч |
|---|---|---|---|---|---|

[1] Төп гомуми белем төп гомуми мәгариф программаларын үзләштергән укучыларны әзерләү дәрәҗәсенә таләпләр һәм эчтәлек элементлары кодификаторы нигезендә, тарих буенча төп дәүләт имтиханы үткәрү өчен

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | баллдан процент |
| 1 | Россия һәм дөнья тарихының борынгы заманнардан алып безнең көннәргә кадәр төп даталарын, этапларын һәм хәлиткеч вакыйгаларын белү | 1.1 | 9 | 9 | 20,5 |
| 2 | Ватаныбыз һәм гомуми тарихның иң күренекле эшлеклеләрен белү | 1.2 | 2 | 2 | 4,5 |
| 3 | Тарихи үсеш барышында формалашкан иң мөһим мәдәният казанышлары һәм кыйммәтләр системасын белү | 1.3 | 2 | 2 | 4,5 |
| 4 | Ватаныбыз тарихы һәм гомуми | 2.2 | 1 | 1 | 2,3 |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

Тарих. 9 сыйныф

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | тарихның мөһим вакыйгаларының эзлеклелеген һәм дәвамлылыгын билгеләү | | | | |
| 5 | Сорауларга җавап биргәндә, уку барышында төрле мәсьәләләрне чишкәндә, төрле тарихи һәм заманча чыганаклар мәгълүматларын (текст, схемаларны; иллюстрация, статистика материалларын) файдалану; төрле чыганаклар мәгълүматларын чагыштыру | 2.3 | 9 | 12 | 27,4 |
| 6 | Тарихи карта белән эшләү | 2.4 | 1 | 1 | 2,3 |
| 7 | Алган белемнәрне планнар | 2.7 | 1 | 3 | 6,8 |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | төзегәндә һәм иҗади эшләр (шул исәптән сочинениеләр) язганда файдалану | | | | |
| 8 | Гомуми тарихи процессларны һәм аерым фактларны үзара бәйләү | 2.8 | 1 | 3 | 6,8 |
| 9 | Тарихи мәгълүматны системалаштыру | 2.10 | 2 | 3 | 6,8 |
| 10 | Өйрәнгән тарихи төшенчәләрнең һәм терминнарның мәгънәсен аңлату | 2.11 | 2 | 2 | 4,5 |
| 11 | Чагыштырылучы тарихи вакыйгалар һәм күренешләрнең уртаклыгын һәм аерымлыгын ачыклау | 2.12 | 2 | 3 | 6,8 |
| 12 | Мөһим тарихи вакыйгаларның сәбәпләрен һәм | 2.13 | 3 | 3 | 6,8 |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

Тарих. 9 сыйныф

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | нәтиҗәләрен ачыклау | | | | |
| | Барлыгы | | 35 | 44 | |

**7. КҮМ биремнәрен катлаулылык дәрәҗәләре буенча бүлү**

Биремнәрне катлаулылык дәрәҗәсе буенча бүлү нигезенә тиешле биремнәрне үтәгәндә укучылар тарафыннан кулланылучы эшчәнлек төрләренең характеристикасы салынган.

Катлаулылыкның нигездәге дәрәҗәсенә имтихан тотучыга датаны, фактны һ.б.ш. ачык рәвештә бирелгән мәгълүматка таянып белү операциясен үтәү тәкъдим ителгән биремнәр керә. 1-22, шулай ук 26 һәм 30 биремнәр шушы дәрәҗәгә кертелгән.

Катлаулылыкның югарырак дәрәҗәсенә укучыдан мәгълүматны мөстәкыйль кабатлау, өлешчә үзгәртү һәм бер типтагы вазгыятьтә куллану таләп ителгән биремнәр керә. Бер үк вакытта чыгарылыш укучысы эшчәнлеге бирем яңартып үзгәртүгә юнәлгән. 23, 24, 25, 27, 28, 29, 31, 32 биремнәр шундыйлардан.

Катлаулылыкның югары дәрәҗәсенә укучылар, алынган белемнәрдән һәм осталыктан файдаланып, яисә яңа кагыйдәләр, гамәлләр алгоритмы, ягъни яңа мәгълүмат булдырып, бер типта булмаган вәзгыятьтә өлешчә-эзләнү гамәлләре башкарырга тиеш булган

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

биремнәр кертелгән. 33, 34 һәм 35 биремнәр шундый булып тора.

**8. Тарих буенча ТДИның дәвамлылыгы**

Имтихан эшен үтәүгә 3 сәгать (180 минут) бирелә.

**9. Өстәмә материаллар һәм җиһазлар**

Өстәмә материаллар һәм җиһазлар кулланылмый.

**10. Аерым биремнәрне һәм тулаем имтихан эшен үтәүне бәяләү системасы**

Әгәр дә сан, саннар тәртибе, сүз (сүзтезмә) дөрес күрсәтелсә, кыска җаваплы бирем дөрес үтәлгән дип санала.

1-23, 25, 27-30 биремнәрнең һәркайсына дөрес җавап биргән өчен 1 балл куела.

24 һәм 26 биремнәрнең һәркайсына дөрес тулы җавап өчен 2 балл куела. Әгәр бер хата киткән булса, җавап 1 балл белән бәяләнә. Әгәр ике һәм аннан күбрәк хата җибәрелсә яки җавап булмаса, 0 балл куела.

2 өлеш биремнәре җавапның тулылыгыннан һәм дөреслегеннән чыгып бәяләнә. 31, 32, 34 биремнәрне үтәгән өчен 0 дән 2 гә кадәр балл, 33 һәм 35 биремнәр өчен – 0 дән 3 кә кадәр балл бирелә.

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте



Бөтен эшне үтәгән өчен иң күп башлангыч баллар – 44.

Төп гомуми белем мәгариф программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен үткәрү тәртибе (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 елның 25 декабрендәге 1394 номерлы боерыгы Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы тарафыннан 2014 елның 3 февралендәге 31206 номерлы карары белән теркәлгән) нигезендә

«48. Имтихан эшләре ике эксперт тарафыннан тикшерелә. Тикшерү нәтиҗәләре буенча экспертлар бер-берсеннән бәйсез рәвештә имтихан эшләре биремнәренә җавапларның һәркайсына баллар куя... Ике эксперт куйган баллар арасында җитди аерма булган очракта өченче тикшерү билгеләнә. Балларда җитди аерма тиешле уку предметы буенча бәяләү критерийларында билгеләнгән.

Өченче эксперт предмет комиссиясе рәисе тарафыннан имтихан эшен элек тикшермәгән экспертлар арасыннан билгеләнә.

Өченче экспертка укучының имтихан эшен элек тикшергән экспертлар куйган баллар турында мәгълүмат бирелә. Өченче эксперт куйган баллар ахыргысы булып тора».

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

31-35 биремнәрнең теләсә кайсын үтәгән өчен баллар аермасы 2 һәм аннан күбрәк булса, өченче эксперт шундый җитди аермага китергән биремнәрне генә тикшерә.

**11. 2016 ел КҮМендә 2015 ел белән чагыштырганда үзгәреш**

Имтихан эшенең 1 өлешендә ике биремнең позициясе үзгәртелгән: тарихи карта, схема белән эшләү биреме 20 позициягә куелган, ә Россия мәдәниятенең 1914-2012 еллар чоры буенча төп фактларын белүгә бирем 21 позициягә урнаштырылган. Әлеге биремнәр позицияләре эшнең структурасын оптимальләштерү: 21 һәм 22 позицияләрдә мәдәният тарихы һәм иллюстрация материалы белән эшләү буенча мини-блок булдыру максатында үзгәртелгән.

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

Тарих. 9 сыйныф

*Кушымта*

**ТАРИХ буенча IX сыйныф чыгарылыш укучыларын ДЙА (дәүләт йомгаклау аттестацияләве) өчен 2016 ел КҮМ вариантының гомумиләштерелгән планы**

*Биремнең катлаулылыгы дәрәҗәләре: Б – база; П – югарырак; В – югары*

| № т/с | Тикшерелүче эчтәлек – курс бүлеге | Тикшерелүче эчтәлек элементлары коды | Эшчәнлекнең тикшерелүче төрләре | Тикшерелүче осталык коды | Биремнең катлаулылык дәрәҗәсе | Биремне чишүгә бирелгән якынча вакыт (мин.) | Бирем өчен максималь балл |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **1 бүлек** | | | | | | | |
| 1 | VIII-XVII гасырлар | 1.1-1.4 | Даталарны белү | 1.1 | Б | 1-2 | 1 |
| 2 | VIII-XVII гасырлар | 1.1-1.4 | Фактларны белү | 1.1 | Б | 1-2 | 1 |
| 3 | VIII-XVII гасырлар | 1.1-1.4 | Сәбәпләрне һәм нәтиҗәләрне белү | 2.13 | Б | 1-2 | 1 |
| 4 | VIII-XVII гасырлар | 1.1-1.4 | Мәгълүматны чыганактан эзләү | 2.3 | Б | 3-4 | 1 |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5 | XVIII гасыр – XX гасыр башы | 2.1, 2.2 | Даталарны белү | 1.1 | Б | 1-2 | 1 |
| 6 | XVIII гасыр – XX гасыр башы | 2.1, 2.2 | Фактларны белү | 1.1 | Б | 1-2 | 1 |
| 7 | XVIII гасыр – XX гасыр башы | 2.1, 2.2 | Сәбәпләрне һәм нәтиҗәләрне белү | 2.13 | Б | 1-2 | 1 |
| 8 | XVIII гасыр – XX гасыр башы | 2.1, 2.2 | Мәгълүматны чыганактан эзләү | 2.3 | Б | 3-4 | 1 |
| 9 | VIII гасыр – XX гасыр башы | 1.1-2.3 | Ватаныбыз тарихының күренекле шәхесләрен белү | 1.2 | Б | 1-2 | 1 |
| 10 | VIII гасыр – XX гасыр башы | 1.5, 2.3 | Россия мәдәнияте тарихының төп фактларын белү | 1.3 | Б | 1-2 | 1 |
| 11 | 1914-1941 еллар | 3.1.1-3.1.8 | Даталарны белү | 1.1 | Б | 1-2 | 1 |
| 12 | 1914-1941 еллар | 3.1.1-3.1.8 | Фактларны белү | 1.1 | Б | 1-2 | 1 |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

Тарих. 9 сыйныф

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 13 | 1914-1941 еллар | 3.1.1-3.1.8 | Сәбәпләрне һәм нәтиҗәләрне белү | 2.13 | Б | 1-2 | 1 |
| 14 | 1941-1945 еллар | 3.1.9-3.1.13 | Фактларны белү | 1.1 | Б | 1-2 | 1 |
| 15 | 1941-1945 еллар | 3.1.9-3.1.13 | Мәгълүматны чыганактан эзләү | 2.3 | Б | 3-4 | 1 |
| 16 | 1945-2012 еллар | 3.1.14-3.1.19, 3.2 | Даталарны белү | 1.1 | Б | 1-2 | 1 |
| 17 | 1945-2012 еллар | 3.1.14-3.1.19, 3.2 | Фактларны белү | 1.1 | Б | 1-2 | 1 |
| 18 | 1945-2012 еллар | 3.1.14-3.1.19, 3.2 | Мәгълүматны чыганактан эзләү | 2.3 | Б | 3-4 | 1 |
| 19 | 1914-2012 еллар | 3.1.15-3.2 | Ватаныбыз тарихының күренекле шәхесләрен белү | 1.2 | Б | 1-2 | 1 |
| 20 | VIII-XXI гасырлар | 1.1-3.2 | Тарихи карта, схема белән эшләү | 2.4 | Б | 3-5 | 1 |
| 21 | 1914-2012 еллар | 3.1.20 | Россия мәдәнияте тарихының төп фактларын белү | 1.3 | Б | 1-2 | 1 |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 22 | VIII-XXI гасырлар | 1.1-3.2 | Иллюстрация материалы белән эшләү | 2.3 | Б | 3-5 | 1 |
| 23 | VIII-XXI гасырлар | 1.1-3.2 | Вакыйгалар-ның эзлеклелеген билгеләү | 2.2 | П | 3-5 | 1 |
| 24 | VIII-XXI гасырлар | 1.1-3.2 | Тарихи мәгълүматны системалаш-тыру (туры китерү) | 2.10 | П | 5-7 | 2 |
| 25 | VIII-XXI гасырлар | 1.1-3.2 | Тарихи мәгълүматны системалаш-тыру (күпчелектән сайлау) | 2.10 | П | 3-5 | 1 |
| 26 | VIII-XXI гасырлар | 1.1-3.2 | Статистик мәгълүмат чыганаклары белән эшләү | 2.10 | Б | 5-10 | 2 |
| 27 | VIII-XXI гасырлар | 1.1-3.2 | Төшенчәләр-не, терминнарны белү | 2.11 | П | 3-5 | 1 |
| 28 | VIII-XXI гасырлар | 1.1-3.2 | Тарихи вакыйгалар-ны һәм күренешләр-не чагыштыру | 2.12 | П | 7-10 | 1 |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

Тарих. 9 сыйныф

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 29 | VIII-XXI гасырлар | 1.1-3.2 | Схема рәвешендә бирелгән мәгълүмат белән эшләү | 2.3 | П | 3-5 | 1 |
| 30 | VIII-XXI гасырлар | 1.1-3.2 | Төшенчәләр-не, термин-нарны белү (бирелгән рәттә артык терминны ачыклауга бирем) | 2.11 | Б | 2-3 | 1 |
| **2 өлеш** | | | | | | | |
| 31 | VIII-XXI гасырлар | 1.1-3.2 | Чыганакны анализлау. Документның атрибутлары | 2.3 | П | 15-20 | 2 |
| 32 | VIII-XXI гасырлар | 1.1-3.2 | Чыганакны анализлау. Текст структура-сына логик анализ | 2.3 | П | 7-10 | 2 |
| 33 | VIII-XXI гасырлар | 1.1-3.2 | Тарихи вазгыятькә анализ. Гомуми тарихи процесслар һәм аерым фактларның үзара бәйләнешен билгеләү | 2.8 | В | 10-15 | 3 |

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

Тарих. 9 сыйныф

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 34 | VIII-XXI гасырлар | 1.1-3.2 | Тарихи вакыйгалар-ны һәм күренешләр-не чагыш-тыру | 2.12 | В | 7-10 | 2 |
| 35 | VIII-XXI гасырлар | 1.1-3.2 | Бирелгән темага җавап бирүнең планын төзү | 2.7 | В | 10-15 | 3 |

Барлыгы **35** бирем; шуларның
бирем төре буенча: кыска җавап белән – **30**, тулы җавап белән – **5**;
катлаулылык дәрәҗәсе буенча: Б – **24**, П – **8**, В – **3**.
Башлангыч максималь балл – **44.**
Биремне үтәү өчен бирелгән гомуми вакыт – **180 минут.**

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте

© 2016 Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте